**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Карамалинского сельского**
**поселения Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д. 8, село Карамалы,
Азнакаевского муниципального
района, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл**
**җирлеге башкарма комитеты**

Үзәк урам, 8, Карамалы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«15» май 2018 ел** **№ 11**

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2017 елның 13 ноябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2017 елның 13 ноябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2.2 пунктта «Халык тыңлаулары» сүзләрен «Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

1.3.2.11 пунктында «гавами тыңлаулар» сүзләрен «иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге халкына җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы җәмәгать фикер алышулары турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр аларның үткәрелүе турында хәбәр иткән көннән алып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Уставы һәм (яисә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм кимендә бер ай һәм өч айдан артык була алмый.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А.Р.Ногманов